Олимпиадные задания школьного тура по татарскому языку для общеобразовательных организаций с обучением на русском языке(для изучающих татарский язык). 2021-2022 учебный год, 8 класс

Максимальный балл –110 б.

Время выполнения – 90 минут

1. Прочитай текст, вместо многоточий допиши пропущенные слова (по 2 балла = 6 баллов)

Бөек рус опера җырчысы Фёдор Шаляпин Казанда туган. Җырчы буларак та, драма актеры буларак та сәләтле булганга күрә, замандашлары аны “җырчы актер” ... атаганнар. Шаляпин Россиянең милли горурлыгына әйләнә. Ул дөньяның иң яхшы опера театрларында чыгышлар ясый.

Фёдор Шаляпин дөнья опера ... зур йогынты ясаган. Аның исемен концерт заллары, урамнар, кунакханәләр һәм теплоходлар йөртә. Опера ... керткән хезмәтләре ... Фёдор Шаляпинның исеме Голливудтагы “Дан аллеясы” йолдызларының берсендә мәңгеләштерелгән.

и ответь на следующие вопросы:

1) Нинди сәнгать ул опера сәнгате?(2 б.)

2) Казандагы опера театры кем исемен йөртә? (2 б.)

3) Фёдор Шаляпин турында син тагын нәрсәләр беләсең? (3-4 предл., за каждое верное предл. 2 б., макс. -8)

4) Фёдор Шаляпинны ни өчен”җырчы актёр”дип атыйлар?(2 б.)

5) Дөньяда аның исеме мәңгеләштерелгән урыннар бармы?(2 б.)

Макс. б. -22.

2. Переведи на русский язык и запиши (14 б.).

1) Язга Габдулла белем ягыннан иптәшләрен узып та китте. 2) Моңа аның сәләте һәм тырышлыгы ярдәм итте. 3) Бервакыт ул җавап бирергә баскач, учительдән:

- Укыймммы, яттан сөйлимме? – дип сорады.

4) – Белсәң, яттан сөйлә, - диде учитель.

5) Габдулла Ушинский дәреслегендәге шигырьне яттан сөйләде.

6) Мактарга яратмаган Әхмәтша учитель, Габдулла сөйләп бетергәч, “молодец!” диде.

7) Габдулла кып-кызыл булды, аңа бик рәхәт иде.

Әхмәт Фәйзи буенча

№	**Предложения**	баллы	**Баллы**
1.		**2**	
2.		**2**	
3.		**2**	
4.		**2**	

5.		**2**	
6.		**2**	
7.		**2**	

3. Напиши антонимы (по 1б., макс. б. -4).

1) тырыш - ... 3) көнчыгыш - ...

2) мәгънәле- ... 4) киң - ...

4. Составь предложения, переставив слова в правильном порядке (по 2 б.- макс. -8 б.).

1. Урын, кеше, хатын-кызларга, тиеш, өлкәннәргә, егет, бирергә, транспортта.

2. Безгә, өйрәнү өчен, кирәк, дәреслекләр, татарча.

3. Яшьтәшләре, укучылар, тыңларга, күбрәк, очрашырга, белән, яраталар, музыка.

4. Ял итү, белән, урманда, рәхәт, дуслар, бик.

5. Найди грамматически правильное начало предложения (2 б.).

....., тырышып эшләргә кирәк.

1) Саф һава керсен дисәң
2) Көн матур булса
3) Мин бу китапны алмаганга
4) Яхшы ял итәр өчен

6. Найди правильный перевод (2 б.).

сөйләр идек-

1) рассказал бы
2) пересказали бы
3) мы рассказали бы
4) может расскажем

7. Допишите пропущенные слова в следующих пословицах (по 2 б.=10 б.).

№	**Слова**	**Макс. кол-во балло в - 10**	**Баллы**
1.	Калган эшкә _____ *(нәрсә?)* яуган.	2	
2.	Вакыт _____ *(нәрсәдән?)* кадерлерәк.	2	
3.	_____ *(кемнән?)* тау да курка.	2	
4.	Шәһәрне макта, _____ *(кайда?)* тор.	2	
5.	Бер карлыгач белән _____ *(нәрсә?)* булмый.	2	

8. По ответной реплике восстанови предыдущую. Мини-диалоги должны соответствовать требованиям этикета (по 2 б. = 12 б.).

№	**Реплики**	**Баллы**

1.	– ...	
	– Әлбәттә, сора. Мин сине тыңлыйм.	
2.	– ...	
	– Кызганычка каршы, мин төгәл генә әйтә алмыйм.	
3.	– ...	
	– Бик рәхәтләнеп.	
4.	– ...	
	– Истәлекле урыннар бик күп. Мин сиңа Казан Кремленнән башларга киңәш итәр идем.	
5.	– ...	
	– Гафу ит, минем бүген эшем күп. Анда экскурсияләргә кушылып тыңларга мөмкин. Барганчы, менә бу китап белән танышырга киңәш итәм.	
6.	– ...	
7.	– Берни түгел.	

9. Переведи и образуй отрицательные формы глаголов

№	**глаголы**	**Баллы** (макс.) (20)	**Сумма** (фактич.) ( )
1.	пычратырга –	**2**	
2.	язгач –	**2**	
3.	бара ала -	**2**	
4.	көлгән –	**2**	
5.	шалтыратса–	**2**	
6.	сорады –	**2**	
7.	кызыксыныр-	**2**	
8.	көткән (вакыйга) -	**2**	
9.	кызыксынасыз –	**2**	
10.	өйрәнергә кирәк –	**2**	

10. Напишите продолжение рассказа (6 -8 предложений, макс. =16 б.)

Татарстанның киләчәге – бездә. ...